| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕМАШЛЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>422658, с. Большой Машляк, ул. Центральная, дом 20 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЗУР МӘШЛӘК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br>422658, Зур Мәшләк, Центральная урамы, 20 нче йорт, |
|---|---|
| Тел.: (84361) 33613, факс: (84361) 33613 , e-mail:BmSl.Rs@tatar.ru | |


**ПРОЕКТ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06.12.2021 Зур Мәшләк авылы №11

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Зур Мәшләк авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының 2004 елның 24 мартындагы “Җирле референдум турында” 23-ТРЗ номерлы Законы,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “ Зур Мәшләк авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 2021 елның 3 декабрендә Зур Мәшләк торак пунктында кабул ителгән, 4 декабрендә Бикчурай, Югары Мәшләк торак пунктларында узган гражданнар җыенында кабул ителгән карарларны тормышка ашыру максатында КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Зур Мәшләк авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыюның кушымта итеп бирелә торган Тәртибен расларга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Зур Мәшләк авылы, Школьная урамы, 13А йорт; Югары Мәшләк авылы, Нариманова урамы, 24а йорт; Бикчурай авылы,М.Горький урамы,50А йорт; Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәгерәсмисайтындаһәм http://pravo.tatarstan.ru.

веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Балык Бистәсе муниципаль районы<br>
Зур Мәшләк авыл җирлеге<br>
Башлыгы М.Г.Заһидуллин

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсемуниципаль
районы Зур Мәшләк авыл
җирлеге Башкарма
комитетының 2021 елның 6
декабрендәге №11 номерлы
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
“Зур Мәшләк авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә
гражданнарның үзара салым акчаларын җыю
Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы

“Зур Мәшләк авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарныңүзарасалымакчаларынтүләү Татарстан Республикасы Балык Бистәсемуниципаль районы “Зур Мәшләк авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан (белем алуның көндезге формасында укучы студентлардан, сәламәтлеге буенча 1 группа инвалидлардан, балачактан инвалидлардан гайре, аларның саны җирлектә яшәүчеләрнең гомуми санының 30 процентыннан артык була алмый) җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм тавыш биргәндә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәйсез рәвештә 2022 елның 14 февраленә кадәр башкарыла.

3. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә бланкы (әлеге Тәртипкә кушымта) гражданнар игътибарына Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәгеhttp://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда игълан итүһәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру (халыкка белдерү) ысулы белән, шулай ук кул куйдырып тапшыру юлы белән яисә почта аша юллап җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчасын күчерү реквизитлары, тулы яисә киметелгән күләмдә бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

4. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Зур Мәшләк авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең лицевой счетына керә.

5. Гражданнар тарафыннан түләүләр акча средстволарын физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган, почта переводларын (исәп-хисап оешмалары) гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар аша, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Зур Мәшләк авыл җирлеге Башкарма комитеты кассасы аркылы яки

https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенчаТатарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү юлы белән башкарыла.

6. Түләү фактын раслаучы булып керем (приход) касса ордерының тамганамәсе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

7. Гражданнарның билгеләнгән срокта кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
“Зур Мәшләк авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге территориясендә
гражданнарның үзара салым акчаларын
жыю Тәртибенә КУШЫМТА

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы“Зур Мәшләк авыл җирлеге”
Муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча
бер тапкыр түләнелә торган түләүне түләү турында
ХӘБӘРНАМӘ №_________

Түләүченең Ф.И.А.и. ____________________________________________________________________________

Адрес: ______________________________________________________________________
____________________________________________________________________________________ниг езендә

Сезгә 2022 елның 14 февраленә кадәр_______________________________________________
______________________________чараларын тормышка ашыруга бер тапкыр түләнелә торган ________сумма күләмендәге түләүне түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк: _______________________________________________________

БИК (банкның таныклаучы коды) алучы банк ______________________________________

Сч. № ______________________________

Сч. № алучы_____________________________________

ИНН ______________________________________

КПП _____________________________________

КБК ______________ ОКАТО ___________________

Түләүнең билгеләнеше ____________________________________________________________________________

Җитәкче _________________ ______________________________________

М.У. (имза) (имзаның расшифровкасы)

- - - - - - - - - - - - - - - - - **кисү сызыгы** - - - - - - - - - - - - - -

Татарстан Республикасы Балык Бистәсемуниципаль районы “Зур Мәшләк авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләнелә торган _________________сум күләмендәге түләүне түләү турында

ХӘБӘРНАМӘ №_________

Түләүченең Ф.И.А.и.

____________________________________________________________

Адрес:__________________________________________________________________________

Алдым “____”________________, 20__ ел

_________________________________________

(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта ертып алына торган төпсә тутырыла һәм Зур Мәшләк авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.*